## Гөлшат Зәйнашева (1928-2005)



Гөлшат Зәйнашева – күренекле татар шагыйрәсе, драматург.

Беренче иҗат тәҗрибәләре — шигырь, җыр, эстрада әсәрләре, пьесалары — вакытлы матбугатта, «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Эстрада», «Клуб сәхнәсе» күмәк җыентыкларда басылып чыккан. 1958 елда лирик шигырьләре тупланган «Тыңларсыңмы җырларымны» исемле беренче китабы дөнья күрә. 1958-2005 елларда авторның төрле жанрда язылган ике дистәдән артык китабы басылып чыккан.

Г. Зәйнашева җыр өлкәсендә актив иҗат иткән. Татарстан һәм Башкортстан композиторлары тарафыннан йөзгә якын шигыренә көй язылган. «Туган җирем — Татарстан» (Александр Ключарев), «Китмә, сандугач» (Рөстәм Яхин), «Менәргә иде Урал тауларына» (Мансур Мозаффаров), «Үз илемдә» (Сара Садыйкова), «Зәңгәр төймә» (халык көе), «Күл буена килсәң иде» (Зиннур Гыйбадуллин), «Кичегеп килгән мәхәббәт» (Бәхти Гайсин), «Кояш гомере» (Фәтхерахман Әхмәдиев), «Аерылмагыз» (Ч. Зиннәтуллина), «Туган авылым урамы» (Ганс Сәйфуллин) һ. б. җырлары җырчыларның репертуарына кергән.

Г. Зәйнашева раматургия өлкәсендә дә актив иҗат итә. «Бәхет кошым», «Кем гүзәл?», «Ирексездән әрәмтамак», «Рамай», «Яшел сукмак», «Гайфи бабай, өйлән давай!», «Җаным җәл түгел сиңа» драма-комедияләре татар театрлары сәхнәсендә уйнала.

Нәниләргә һәм кече яшьтәге мәктәп балаларына атап язылган шигырьләре һәм җырлары «Асия» (1973), «Кояш гомере» (1975), «Бөҗәкләр концерты» (1984), «Гимназиядә дуслаштык» (1996), «Әбиемне яратам» (1997) китапларында тупланып бирелгән.

### Төп басма китаплары

Тыңларсыңмы җырларымны: җырлар, такмаклар. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1958. – 39 б.

Без Казан кызлары: җырлар. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1961. — 56 б.

Очраклы хәлләр түгел: пьесалар. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1964. — 40 б.

Җырлап яшик!..: шигырьләр, җырлар. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1971. —79 б.

Асия: шигырьләр. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1973. — 24 б.

Пьесалар. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1974. — 175 б.

Гөлләр иле: шигырьләр, җырлар, — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1977. — 192 б.

Күңелле ял итегез!..: эстрада әсәрләре. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1979. - 112 б.

Җырчы миләш: шигырьләр – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1982. – 80 б.:

Бөҗәкләр концерты: шигырьләр– Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1984. – 15 б.

Сара Садыйкова: тормышы һәм иҗаты. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1987 — 144 б.

Илле җыр: җырлар (ноталары белән). — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1988. — 120 б.

Әдәм күлкесе: эстрада әсәрләре. — Казан: Газета-журнал нәшрияты, 1995. — 110 б.

Әбиемне яратам: шигырьләр. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1997. — 54 б.

Мәхәббәт һәм җыр: шигырьләр, җырлар. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2000. — 192 б.

Сайланма әсәрләр: җырлар, шигырьләр, пьесалар / төз. В.Шәрипова. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2006. — 383 б.

## Библиография

Авзалова-Нигъмәтҗанова, З. «Аерылмагыз» - безнең җыр / З.Авзалова-Нигъмәтҗанова // Сөембикә. – 2018. – №2. – 38-39 б.

*Җырчы Әлфия Авзалова башкарган шагыйрә Гөлшат Зәйнашева сүзләренә, композитор Чулпан Зиннәтуллина көенә язылган «Аерылмагыз» җыры тарихы.*

Вәлиуллина, И. «Җыр язып йокларга ятты...» / И.Вәлиуллина // Ватаным Татарстан. – 2018. – №152 (20 октября). – 6 б.

*Шагыйрә Гөлшат Зәйнашева турында.*

Сабирова, А. «Аның шигырьләре җыр өчен яратылган» / А.Сабирова // Шәһри Казан. – 2018. – №116 (23 октября). – 6 б.

*Татар филармониясендә шагыйрә Гөлшат Зәйнашеваның 90 еллыгына багышланган кичә узуы турында.*

Сальмушев, Р. Учактай җылы Гөлшат апа / Р.Сальмушев // Мәдәни җомга. – 2018. – №35 (7 сентября). – 17 б.

*Шагыйрә Гөлшат Зәйнашева турында.*

Сәхәбиева, З. Җыр бүләк итәм / З. Сәхәбиева // Сөембикә. – 2018. – №1. – 44-45 б.

*Шагыйрә Гөлшат Зәйнашева сүзләренә Луиза Батыр-Болгари көенә иҗат ителгән «Хушлашмый китәм» җыры тарихы турында.*

Ханнанов, Р. Китмә, сандугач!.. / Р.Ханнанов // Казан утлары. – 2018. – №1. – 121-125 б.

*Шагыйрә Гөлшат Зәйнашева турында.*

Әхмәтҗанова, Н. Җырга бирде бар көчен / Н. Әхмәтҗанова // Казан утлары. – 2013. – № 10. – Б. 140-143.

*Шагыйрә Гөлшат Зәйнашеваның иҗаты турында. Республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләген хатын-кызлардан беренче булып 1991 елда Г.Зәйнашева алды («Илле җыр» китабы өчен).*

## Гульшат Зайнашева (1928-2005)

Гульшат Зайнашева - татарская поэтесса и драматург.

Первые стихи, песни, пьесы, эстрадные произведения Г.Зайнашевой были напечатаны в конце 50-х годов в периодической печати и в сборниках «Кунелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Эстрада», «Клуб сәхнәсе».

Г.Зайнашева – автор более десятка книг. Поэтесса плодотворно трудилась над созданием песенных текстов. Более 50 стихов поэтессы положены на музыку композиторами Татарстана и Башкортостана. Ее песни, посвященные родной земле: «Туган жирем – Татарстан» (музыка А.Ключарева), «Китмә, сандугач» (музыка Р.Яхина), «Менәргә иде Урал тауларына» (музыка М.Музаффарова), «Уз илемдә» (музыка С.Садыковой), теме любви: «Зәнгәр шәл» (музыка народная), «Күл буена килсәң иде» (З.Гибадуллина), «Яшь гомер» (музыка З.Гибадуллина), «Кичегеп килгән мәхәббәт» (музыка Г.Гайсина), детям: «Кояш гомере» (музыка Ф.Ахмадиева) – наглядно отражают богатство поэзии Г.Зайнашевой музыкальными образами.

## Эти книги Вы можете взять в нашей Республиканской детской библиотеке

Очраклы хәлләр түгел: пьесалар. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1964. — 40 б.

Җырлап яшик!..: шигырьләр, җырлар. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1971. —79 б.

Асия: шигырьләр. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1973. — 24 б.

Гөлләр иле: шигырьләр, җырлар, — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1977. — 192 б.

Күңелле ял итегез!..: эстрада әсәрләре. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1979. - 112 б.

Җырчы миләш: шигырьләр – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1982. – 80 б.:

Бөҗәкләр концерты: шигырьләр– Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1984. – 15 б.

Әбиемне яратам: шигырьләр. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1997. — 54 б.

Мәхәббәт һәм җыр: шигырьләр, җырлар. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2000. — 192 б.

Сайланма әсәрләр: җырлар, шигырьләр, пьесалар / төз. В.Шәрипова. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2006. — 383 б.